**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 29 ноябрендәге
гражданнар җыены карарына үзгәрешләр
кертү турында

22.06.2024 № 124

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 13 июнендәге 4 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында 2023 елның 29 ноябрендәге 109, 110 номерлы карарлары белән җыелган үзара салым акчаларын куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын уздыру" турында карары буенча түбәндәгечә кулланырга

**- Торак пункт территориясен төзекләндерү ( МТЗ 82.1 тракторын сатып алуны финанслау).**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмәгә ярашлы: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 300 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 205 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«риза» - гражданнар җыенының 164 катнашучысы тавыш бирә;
«каршы» - җыенның 0 катнашучысы тавыш бирә.
Бу нигездә, гражданнар җыенын:

1. Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга
2. "Сез 2023 елның 29 ноябрендәге 109, 110 номерлы гражданнар җыены карарлары нигезендә җыелган үзара салым акчаларының бер өлешен түбәндәгечә кулланырга ризамы?" дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

Карар кабул ителгән дип санарга.

**- Торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторын сатып алуны финанслау).**

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Турай авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгы _______________ Г.Б. Куляшова